# Шүрәле

1. Безнең Тукай бәйрәменә
   Килгән икән Шүрәле.
   Бәйрәмне безнең бозмакчы,
   Кыланышын күр әле.

Кушымта: Шүрәле, Шүрәле,
Шүрәлене күр әле.
Көти, көти уйныйк диеп,
Торган була бит әле.

2. Олы бәйрәм хөрмәтенә
   Усаллыгын киметкән,
   Гафу итәрбез, Шүрәле,
   Дуслар белән биесәң.

3. Әкияттән чыктыңмы син,
   Урманнан киләсеңме?
   Әгәр булсаң чын Шүрәле,
   Кытыклап кара безне.